**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

# КАРАР

**« 23 » июнь 2023 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Арча шәһәр Советының 2022 елның 17 августындагы 73 номерлы карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының, шәһәр җирлеге торак пунктларында яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын тикшерүдә катнашу хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) 2023 елның 31 июленә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2023 елның 31 июлендә 16. 00 сәгатьтә ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча уздырырга.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм гавами тыңлауларда (җәмәгать фикер алышуларында) катнашуга гаризалар язма рәвештә 2023 елның 30 июлендә 16.00 сәгатькә кадәр эш вакытында 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан

Республикасы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт (тел.8(84366) 3-16-35) адресы буенча җибәрелә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча эшче төркем составын кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында Арча шәһәр Советы карары проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Район җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

«Совет
города Арск

И.Г.Нуриев

Арча муниципаль районы
«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгының
23 июнь 2023 ел, № 2
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча эшче төркем составы

Эшче төркем рәисе:

| | |
|---|---|
| Касыймов Р.Ф. - | Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе |

Эшче төркем секретаре:

| | |
|---|---|
| Нигъмәтҗанова Г.Х.- | «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әмиров А.Г. - | Арчаның 4 нче сайлау округы депутаты; |
| Гарипова Г.Ф. - | Арчаның 7 нче сайлау округы депутаты; |
| Хәкимов И.Ү. - | Арчаның 14 нче сайлау округы депутаты |